**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## О проведении русского народного праздника «Каравон»

В целях проведения в 2024 году русского народного праздника «Каравон» и на основании статьи 2 Закона Республики Татарстан от 19 февраля 1992 года № 1448-XII «О праздничных днях и памятных датах Республики Татарстан» **постановляю**:

1. С учетом предложений Министерства культуры Республики Татарстан, органов местного самоуправления и общественных объединений провести русский народный праздник «Каравон» 26 мая 2024 года в селе Никольское Лаишевского района Республики Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить организацию подготовки и проведения русского народного праздника «Каравон».

3. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» организовать освещение в средствах массовой информации проведения русского народного праздника «Каравон».

4. Предложить органам местного самоуправления, общественным объединениям и организациям принять активное участие в подготовке и проведении русского народного праздника «Каравон».

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
05 марта 2024 года
№ 174

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

2024 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2024 елның 26 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 05 март
№ 174